

# I

**Н**әкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен, «тавыклары җырлай» диләр.

Гәрчә анда тугмасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.

Ул авылның, – һич онытмыйм, – һәр ягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.





Зурмы? – дисәң, зур түгелдер, бу авыл
бик кечкенә,
Халкының эчкән суы бик кечкенә – инеш кенә.

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың
бер чиләк.

Бик хозур! рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы,
нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.

Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр[1].

---


[1] *Гонҗәләр* – ачылып җитмәгән чәчәкләр.

Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләк-
ләр, килеп, киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.

Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары[1].

Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня,
цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.



[1] *Садаи хушлары* – ягымлы тавышлары.



Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби,
Биниһая, бихисаптыр[1], гаскәри Чыңгыз кеби.

Кылт итеп искә төшәдер намнары[2], дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң,
бөтен сауләтләре[3].

Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә
Хакның бәндәсе.

---

[1] *Биниһая, бихисаптыр* – очсыз-кырыйсыздыр, исәпсез-хисапсыздыр.

[2] *Намнары* – мактаулы исемнәре.

[3] *Сауләтләре* – батырлыклары.